КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 4 июнь г.Казань № 404

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2021 ел, 09 декабрь, 1206 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2021 ел, 9 декабрь, 1206 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 сентябрь, 1027 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.1 пунктта:

таблицаның «Бишенче квалификация дәрәҗәсе» юлының 5 нче графасында «23 362» саннарын «58 000» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Фәнни оешмага аерымланган бүлекчә башлыгы урынбасары (мөдире) вазыйфасы кертелгәндә аның база оклады аерымланган бүлекчә башлыгының (мөдиренең) база окладыннан 0,8 күләмендә билгеләнә.»;

5.3 пунктта:

беренче абзацта «квалификация дәрәҗәләре» сүзләреннән соң «, бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

таблицаның «Фәнни хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары» юлының 1 нче графасына «, бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

5.6 пунктта:

беренче абзацта «фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре» сүзләреннән соң «, бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

таблицаның «Фәнни хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме» юлының 1 нче графасына «, бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

5.7 пунктта:

беренче абзацта «структура бүлекчәләре җитәкчеләре» дәрәҗәсе» сүзләреннән соң «, бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

таблицаның «структур бүлекчәләр җитәкчеләре» квалификация дәрәҗәсенә кертелгән фәнни хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары» юлының 1 нче графасына «, бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

5.8 пунктта:

беренче абзацта «фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре» сүзләреннән соң «, бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

алтынчы абзацта «фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре» сүзләреннән соң «, бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта «фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре» сүзләреннән соң «, бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

5.9 пунктта:

беренче абзацта «структура бүлекчәләре җитәкчеләре» сүзләреннән соң «, бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

таблицаның «Фәнни хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфалары, профессор-укытучылар составы хезмәткәрләре вазыйфалары» юлына «структур бүлекчәләр җитәкчеләре» сүзләреннән соң «бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш» сүзләрен өстәргә;

5.10 пунктта:

таблицаның 3.12 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

утыз беренче абзацта «фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре» сүзләреннән соң «, бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

утыз өченче абзацта «фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре» сүзләреннән соң «, бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

5.11 пунктның беренче абзацында «фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре» сүзләреннән соң «, бишенче квалификация дәрәҗәсенә

кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш,» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $5.11^{1}$ пункт өстәргә:

«5.111. Бишенче квалификация дәрәҗәсендәге структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һөнәри квалификация төркеме буенча аерымланган бүлекчә башлыгына (мөдиренә) башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен 6 000 сум күләмендә акчалата түләү билгеләнә.

Фәнни оешмага аерымланган бүлекчә башлыгы урынбасары (мөдире) вазыйфасын керткәндә, аңа аерымланган бүлекчә башлыгы (мөдире) вазыйфасы буенча башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру түләүләренең 0,8 күләмендә кызыксындыру түләве билгеләнә.

Бишенче квалификация дәрәҗәсендәге структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме буенча аерымланган бүлекчә башлыгына (мөдиренә) һәм аерымланган бүлекчә башлыгы (мөдире) урынбасарына әлеге пунктта каралган акчалата түләүләр, аларның эшчәнлекләре нәтиҗәләрен исәпкә алып, фәнни оешма җитәкчесе тарафыннан билгеләнә һәм ай саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен башкарыла.»;

7.1 һәм 7.2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Фәнни оешма җитәкчесенең, аның урынбасарларының һәм баш бухгалтерның хезмәткә түләү шартлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 30 март, 195 нче карары нигезендә билгеләнә.

7.2. Фәнни оешма җитәкчесенең, аның урынбасарларының һәм баш бухгалтерның финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары һәм календарь ел өчен хисаплана торган айлык уртача хезмәт хакы һәм фәнни оешма хезмәткәрләренең уртача айлык хезмәт хакы нисбәтенең иң чик дәрәҗәсе 8 тапкырлыкта билгеләнә (тиешле җитәкченең, аның урынбасарларының, баш бухгалтерның хезмәт хакын исәпкә алмыйча).»;

7.3 – 7.7 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

Татарстан Республикасы дәүләт фәнни оешмалары исемлегенең 2 – 4 пунктларын, аларда эшләүчеләргә күрсәтелгән карар белән расланган хезмәткә түләүнең яңа системасы билгеләнә, үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин